ISSN 0868-4545



Салават күпере

Арча җиренә рәхим итегез!



Айрылып китсәм дә синнән гомеремнең таңында мин,
И Казан арты! сиңа кайттым сөеп тагын да мин.

Габдулла Тукай.

* * *

Безнең Татарстан илендә бик күп районнар бар. Шуларның иң данлыклысы Арча булыр. Тукаебызның туган ягы.

Курсави, Мәрҗани, Күлтәси кебек галим-мәгърифәтчеләрне биргән як.

Татарстанның халык язучылары Гомәр Бәширов, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов һәм тагын утызлап язучы шушы районнан.

Илебезгә 8 Герой, иллелеп галим, дистәдән артык атказанган һәм халык артистлары биргән район ул.

Әйдәгез, без дә Арча районы буйлап сәяхәткә китик.



Татарстан Республикасының Арча районы картасы

Туган ягым – яшел бишек.

Гомәр Бәширов.

* * *

Татарстанда Тукай Казан арты дип билгеләгән бер як бар. Себер тимер юлы белән Казаннан алтмыш чакрымнар киткәч, Арча булыр. Автобуска утырып шул чама баргач, Кенәрләр, Әтнәләр булыр. Әнә шул инде ул – Казан арты. Дан булып җырларга кергән Иделләре, Агыйделләре, Чулманнары да юк аның, көмеш күлләре дә күренми. Әмма урманнары бик матур, кешеләре киң күңелле. Булдыклылык, тырышлык дисәң, аларга тиң бар микән?!

Гариф Ахунов.

* * *

... «Масра (Арча районындагы авыл исеме – ред.) басу» тын, бик тын. Шундый тын, дөньяның зыңлаган тавышы ишетелә, дөнья сабырлык, акыл чәчә, кызыл шар инде күмелеп бара, җир әйләнә, ә мин шушы мәһабәт тынлык уртасында торналар төшкән җирдә берүзем басып торам.

Бу – минем туган җирем...

Мөхәммәт Мәһдиев.

© "Салават күпере", 2000 ел



Яратыгыз Туган җирегезне!

Арча ягы гасырлар буена милли мәдәнияте һәм тырыш халкы белән дан казанган. Тукай да юкка гына:

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрдем,
Билгесездер, кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем, – диеп язмаган бит инде.

Казан арты – минем дә туган җирем, минем белән бергә фоторәсемгә төшкән бу балаларның да туган җире. Үз туган җире һәр кешегә дә кадерле була инде ул.

Әмма туган җирне тагын да көчлерәк ярату өчен бик тырышып укырга, үз ягыңның тарихын, гореф-гадәтләрен, халкын, күренекле шәхесләрен белергә кирәк. Ә безнең якта кешеләр эшчән, һөнәрле, сабыр, киң күңелле. Сезнең әби-бабаларыгыз, әти-әниләрегез алар. Туган җирегезне яратыгыз, халкыбыз белән горурланыгыз, илгә-көнгә игелекле булып үсегез, нәни дусларым!

Арча районы хакимияте башлыгы
Илһам Наил улы Сабиров.

Күгең аяз булсын!

– Айсылу, кояшыңны зуррак яса, рәсемең яктырып китәр. Ә син, Тимур, менә бу сыек зәңгәреңне ал әле, күгең аяз булсын.

Арчадагы сәнгать мәктәбенең сынлы сәнгать сыйныфында дәрес бара. Балалар кулындагы кыл-каләмнән ак кәгазьгә гаҗәеп матур төсләр түгелә.

Бәхетле дә инде бу Арча малайлары һәм кызлары. Бер дигән сәнгать мәктәбе бар монда. Анда 500 дән артык укучы йөри. Алар җырлый, бии, гармунда уйный, рәсем ясый, кыскасы, мәш киләләр. Гап-гади агач кисәгеннән генә дә әллә нинди хикмәтләр эшләгәннәр.

Ә мәктәпләре зур, якты. 254 урынлы тамаша залын гына күр әле: сәхнәсе иркен, утыргычлары йомшак. Аларга бер бөртек тузан кундырмыйлар, тап төшермиләр – тамаша-фәлән булмаганда өсләренә ябып торалар.

Шушы гүзәл йортның кечкенә хуҗаларына безнең дә теләк бер: кояшыгыз рәсемдәге кебек балкып торсын, күгегез аяз булсын!





Бу йортка сәнгать дигән тылсымлы, гүзәл дөнья сыйган.



Мөгаллимова Резеда, 12 яшь.

Сәнгать мәктәбенә йөрүче балаларның кайбер рәсемнәрен сезгә дә күрсәтәбез.





Мифтахов Тимур , 9 яшь.

Иркә песи


Минем бар бер песием,
Аның исеме Иркә.
Аның белән уйныйбыз
Кичен, көндез һәм иртән.

Мәктәптән кайтышыма,
Ул мине көтеп тора.
Мыр-мыр итеп мырылдап
Койрыгын борып тора.

Эльмира Гайнуллина.
IV А сыйныфы.



Габдерәшитова Лилия , 12яшь.



Каримова Люция , 12яшь.



«Минем өчен тормышта ике нәрсә гомер буе могҗиза булып саклanып килә: берсе – Чишмә, икенчесе – Әлифба. Аларны бер генә кеше дә уйлап чыгара алмый, алар дөньяга үзләреннән үзләре туалар һәм шулай гомер буе яшиләрдер кебек тоела иде миңа. Өстәвенә алар икесе дә сусауны басу өчен яратылган: Чишмә – суга сусаганны, Әлифба – белемгә сусаганны».

Гариф Ахунов.



Әлифбаның монысы – безнеке, үзебезнеке!



Ә болары башка халыкларныкы.

Илһамга инде алты яшь тула. Ул дәү малай. Әлифба китабындагы хәрефләрне дә таный инде.

Ай-һай, әйбәт Илһамның Әлифбасы!

– Илһам, Илһам, бу Әлифбаны кем язган икән?

– Кем булсын инде. Минем әтием язган!

– Нишләп алай дисең, Илһам?

– Аны миңа әтием алып кайтып бирде бит!

Укучым! Син дә Әлифбаны үз әтиең язган дип уйлыйсыңдыр, бәлки?! Әйдәгез, моның чын дәресен ачыклыйк әле!


Яраткан әлифбабызның туган җире

Гаҗәеп кызыклы кешеләр яши Арчада. Син апаңны, абыеңны, әти-әниеңне, хәтта әби-бабаңны хәреф танырга өйрәткән кешеләрнең дә монда яшәгәнен белмисеңдер дә әле. Рәмзия Вәлитова белән Сәләй Вагыйзов алар. Меңнәрчә кешене хәреф танырга өйрәткән, дөньяга күзен ачкан Әлифбаны төзегән кешеләр. Ирле-хатынлы бу могтәбәр Укытучыларның берсенә – 86, икенчесенә – 92 яшь.

Әгәр Әлифба музее бар икән дисәләр, ул кайда була инде? Әлбәттә, Арчада – син укыган яки укыйсы Әлифбаның туган җирендә.

Шәп музей бу. Педагогия көллиятендә ачылган ул. Монда сез иң беренче Әлифбаны да күрә аласыз. Еллар узу белән саргайса да, күпләрнең күңелен агарткан иман шарты бу.





Бу рәсемнәрдә Рәмзия апагыз белән Сәләй абыегызны һәм аларның эш өстәлен күрәсез.

20 нче елларда исә Кызыл Армия сугышчыларының, крестьяннарның, эшчеләрнең, яшьләрнең һәркайсының үз Әлифбасы булган.

Ә Рәмзия апагыз белән Сәләй абыегыз төзегән Әлифбаны 1964 елдан укый башлыйлар. Музейның бер почмагында әнә шул Әлифба язылган өстәл тора. Аның өстендә кәгазь-каләм, астында идәннән салкын бәрмәсен өчен кигән җылы каталар ята. Бу өстәл янында күпме йокысыз төннәр узган, күпме күз нуры түгелгән. Монысын шушындый игелекле эшкә алынган Рәмзия апагыз һәм Сәләй абыегыз үзләре генә беләдер.

У-у-у!.. Монда әлифбаларның ниндие генә юк. Дөньяның төрле төбәкләреннән җибәргәннәр аларны. 100дән артык әлифба. 100дән артык халыкның зиһенен арттырган, белемгә сусаганнарга татлы ширбәт биргән, күңелләргә игелеклелек, мәрхәмәтлелек орлыклары чәчкән Галиҗәнап китап!

Алар арасында иң матуры, иң шәбе – үз Әлифбабыз. Һәрхәлдә безгә шулай тоелды.




Шүрәлене кем коткара?

Борын-борын заманда әле синең әбиең көлдән борчак чүпләгәндә, бабаң койма башында уйнап утырганда, әтиең бишектә җылап яткан чагында, әниең әбиең алдында мәми сорап утырганда ук Былтыр атлы егет яшәгән ди. Ул урманда Шүрәле агайны очраткан. Аның бармаклары бик озын булган. Былтыр Шүрәленең әнә шул озын бармакларын агач ярыгына кыстырган.

Наил атлы малай бу турыда әллә кайчан белә иде инде. Аңа Шүрәле бик тә кызганыч булган. Һәм ул бер дә бер көнне Шүрәлене коткарырга – бармакларын ярыктан чыгарырга уйлаган. Ләкин ничек итеп? Бармаклар бик шәп кысылган бит! Агач, бүрәнә ярыгыннан аларны ничек итеп чыгарырга була соң? Каты итеп кулыннан тартсаң, кулы авыртачак һәм Шүрәле бөтен урманны яңгыратып кычкырып җибәрәчәк! Аның кычкырган тавышына урмандагы бар киек-җәнлекләр, җанварлар да куркып качып китәчәкләр. Арча урманы буп-буш һәм күңелсез булып калачак бит!

Дустым! Әйтче, ничек коткарыйк соң Шүрәлене, ә?

Наил атлы малай, киңәш-ярдәм сорап, туп-туры Тукай-Кырлайга юл тоткан ди.



Менә алар – Шүрәле күргән Кырлай балалары.







Кырлай мәргәннәре.

Шүрәленең ничә мөгезе бар?

– Сезнең урманда Шүрәле күргәнегез бармы?

Тукай-Кырлай авылы балаларыннан шулай дип сораган идек. Беләсезме, ни диләр:

– Бар! – диләр.

Шаккаттык. Гаҗәпкә калдык. Бер мөгезлесен дә, ике мөгезлесен дә күргәннәр. Хәтта бер малайга өч мөгезлесе очраган. Хәер, нигә гаҗәпләнергә. Тукай яшәгән авылда яшәсеннәр дә, бәләкәй Апуш йөргән урман-кырларда йөрсеннәр дә, күргәнебез юк дип, тормаслар бит инде.

Тапкыр, зирәк булу өстенә талантлы да икән Кырлай балалары. Безгә биеп, җырлап, шигырьләр сөйләп күрсәттеләр. Балалар бакчасына йөриләр, шунда өйрәнәләр икән. Ә бакчалары авылда яшәүче иң уңган хуҗабикәләрнең өе кебек чиста, җылы, күңелгә ятып тора.

Укучым! Ә синең Шүрәле күргәнең бармы? Булса, ничә мөгезле иде ул! Гомумән, Тукай язган Шүрәле ничә мөгезле булган әле? Һәм сезнең урмандагы Шүрәленең ничә мөгезе бар!

Ә инде Шүрәлене бөтенләй күргәнең булмаса нишлибез? Хәер, бер дә аптырап тормыйбыз – җәйге каникуллар вакытында... әйе, әйе, җиктереп пар ат, Арчага китәбез, туптуры карап. Шүрәле урманына таба юл алабыз, Алла боерса.






Тукай һәм Арча


«Бәләкәй Тукай». Рәссам Х.Казаков.

Бу ике исем бер-берсеннән аерылгысыз, алар мәңге янәшә. Республикабызда бөек шагыйрьнең Берләштерелгән дәүләт музее филиалы булып саналган өч музее булса, шуларның икесе – Арча районында. Болар – әдипнең Кушлавычтагы музей-йорты һәм яңа Кырлайдагы мемориаль үзәге.

Иң әүвәл Кушлавычка барыйк әле. Габдулла Тукай 1886 елның апрелендә шушы авылда Мөхәммәтгариф мулла гаиләсендә дөньяга килә. Ул тууга биш ай үтми, әтисе үлә. Габдулла ике яшь тулганда, аны ярлы карчык Шәрифәгә калдырып, әнисе Мәмдүдә яңадан кияүгә чыга. Бераздан ул Габдулланы үз янына – Сасна авылына алдыра. Әмма бер елдан әнисе дә үлеп китә.

Тукайның Кушлавычтагы музей-йорты Мөхәммәтгариф мулланың өе урынында, элеккечә итеп, яңадан торгызыла. Зур миче булган чиста, җылы татар өе бу. Шунда ук шагыйрь әтисенең шәхси әйберләре.


Кушлавыч. Тукай туган нигез.


Кушлавыч музей-йортында шагыйрь туган йортның эчен менә шулай күрсәтергә тырышканнар.



Менә ул – Кырлайдагы музей.

Әнисе үлгәч, Габдулла Өчиле авылында, бабасында яшәп ала. Ике ел Казанда үзен асрамага алган үги əти-əнисендə тора. Аннан Кырлай авылы кешесе Сәгъди абзый аны үзенә алып кайтып китә.

Кырлайда аның дөньяга күзе ачыла. Бу авылның табигате, Сабантуйлары күңелен әсир итә. Монда узган елларын ул соңыннан сагынып-сагынып искә ала.

Кырлай музеен карагач, шагыйрьнең бөтен тормышы, иҗаты күз алдына килә. Монда аның үзе исән чакта басылган китаплары, шәхси әйберләре, шул чордагы тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары. Сезгә яхшы таныш булган Шүрәле дә монда үзенә җылы урын тапкан.



Сәгъди абзый йортының эчке күренеше.



Кырлайдагы Тукай музее алдына куелган һәйкәл. Бакый Урманче эше.




«Шүрәле асрап яткан карурман» менә шушы инде ул.



Арча төбәге кешеләр тарафыннан безнең эрага кадәр үк үзләштерелә башлаган. Археологларның раслауларына караганда, Казансу елгасы буе XII-XIII йөзләрдә татар халкының борынгы бабалары болгарлар тарафыннан ныклап үзләштерелгән. Болгарларның чик буе ныгытмасы буларак Арчага XIII йөз башларында нигез салына. Арча крестьяннарның җир һәм азатлык өчен, социаль, милли һәм дини изүгә каршы күп санлы баш күтәрүләрнең шаһиты була.

1930 елдан ул Татарстанның район үзәге.



Рәссам Фәрит Муллахмәт

АВЫЛ ИСЕМНӘРЕ КАЯН КИЛЕП ЧЫККАН?

Арча – галим Р.Фәхретдинов Арча атамасының барлыкка килүен артыш үсә торган тауга мөнәсәбәтле итеп карый (төрки телләрдә арча «артыш» мәгънәсендә кулланыла).

Кәче – безнең уебызча, авыл үзенә исем итеп төрки кабилә-кавем атамасы булган кәче сүзен алган.

Сеҗе – бу авыл башта Мурия Мусич (бу кеше Иске Му авылыннан килгән, шушында тегермән салган) дип атала. Монда чирмешләрнең солы басуы булган. Сеҗе марича солы басуы дигән сүзне белдергән.

Мөндеш – бу атама төрки мен кабилә утырган деш-теш (төш) мәгънәсен бирә. Бу тирәләргә, димәк, төркиләрнең мин-мен исемен алган кабилә-кавемнәре килеп утырган.

Күлтәс – борынгы заманда авыл тирәсендә вак күлләр күп булган. Авылның исеме дә күл сүзеннән, дөресрәге «тәч күл» дигәннән чыккан, имеш. Тора-бара бу Тәчкүл атамасы Күптәчкә әйләнеп киткән.

(**Фирдәвес Гарипованың** «Авыллар һәм калалар тарихыннан» дигән китабыннан.)









Һәркем сокланыр як

Арча районы Татарстанның төньяк-көнбатышында урнашкан. Ул Марий-Эл Республикасы, Биектау, Саба, Балтач, Әтнә районнары белән чикләнә. Район аша Казансу, Ашыт, Шушма елгалары ага. Монда 51 меңнән артык кеше яши. Районда 130 авыл бар. Халыкның төп шөгыле – игенчелек.

Арчалар үзләре яшәгән төбәкне яңартып, төзекләндереп, матурлап торалар. Үзләренең өр-яңа кирпеч заводлары бар. Район үзәгеннән кай тарафка гына китсәң дә, асфальт юлдан барасың. Авылларда газ яна.

Милли читек-кәвешләр, түбәтәйләр, камзулларны да кайда тегәләр дисезме? Әлбәттә, Арчада.

Дуслар! Юри кызыксынып карагыз әле. Сезне укытучы яки укытачак укытучыларның да күбесе Арча педагогия көллиятен тәмамлагандыр әле. Хәтта бөек җырчы Федор Шаляпин да 1895 елда Арчада реаль училищеда укыган.



Мәктәбе дә мәктәбе



Бер әкият сөйлимме. Борын-борын заманда яшәгән ди, булган ди Ләйсән исемле бер кыз. Үзе дә иseme кебек бик матур икән. Ә ул укыган мәктәпне күрсәгез, «ах» итәрсез. Мәрмәр стеналар, мәрмәр баскычлар. Кая карама – гөлләр. Ә парталар бер генә урынлы. Һәркемнең үзенеке. Дәрес вакытында сиңа берәү дә комачауламый. Ашханәгә керсәң – ә анда берьюлы 200 бала сыя – тәмле аш исләреннән башың әйләнә, спортзалга сугылсаң, йөгерәсе килә. Ә тамаша залы. Өр-яңа йомшак утыргычларга утырып, концерт караву үзе ни тора.

Бу мәктәпнең директоры Илгиз Мәрдән улы Миңнебаев – зәңгәр күзле, кара бөдрә чәчле, һәрвакыт елмаеп тора торган сөйкемле, җитез, өлгер абый. Менә шул абый мәктәптә балаларның ни эшләгәнен телевизордан гына карап утыра икән. Башкалар да карыйлар. 19 телевизор бар монда. Кабельле телевидение дип атала ул.

Тагын ниләр бар дисезме? Китапханә, уку залы, металл һәм агач эшкәртү станоклары, тегү остаханәсе, кулинария, компьютер бүлмәләре, тракторлары, микродулкынлы мичләре... Ни генә юк монда. Барысы 10 түгәрәк, 6 студия эшли.

Ә укучыларның кулыннан гөл тама. Мәсәлән, гап-гади мех кисәгеннән әллә нинди җәнлек, җанварлар ясаганнар, сөлге-тастымаллар чиккәннәр.

Чү, дуслар, без сезне алдадык бит. Хәер, журналыбызның апрель саны булгач, нигә әле бераз шаярып алмаска. 1 апрель көнне үзегез дә алдыйсыздыр әле. Юк андый мәктәп. Һи, менә тагын алдадык инде. Мәктәбе бар – Арчадагы 5 нче татар гимназиясе ул. Тик мондый әкият кенә юк. Ә мәктәп нәкъ менә әкияттәге кебек.

Ләйсән дигән теге кыз да бүген шушында әйбәт кенә укып йөри. Шигырьләр дә яза. Ләйсәннең һәм аның дусларының шигырьләрен сез дә укып карагыз.

Туган җирем

Туган илем, туган җирем,
Тауларым һәм суларым.
Яратам шул сезне мин,
Сөя минем йөрәгем.

Монда көн дә кояш балкый,
Нурларын сибә.
Ә болыннарында йөрү –
Сихри бер дөнья.

Чишмәсенең сулары
Шифалы да, татлы да.
Уч төбенә салып эчсәң,
Татлысы юк аннан да.

Иңнәренә чиләк асып,
Җырлый-җырлый матур җыр.
Кызлар төшә бу чишмәгә
Су алырга көлешеп.

Ашкына күңелләрем
Туган-үскән йортыма,
Кайтыр идем хәзер үк
Шушы туган ягыма.

Альбина Сөнгатова.
VII А сыйныфы.



Әнием

Көн дә төшемдә күрәм
Кадерле әниемне.
«Кызым», – дип кочаклап ала
Төшемме бу, өнемме?

Мин дә аны кочаклыйм,
Юк, төшем түгел икән.
Бу дөньяда миннән дә
Бәхетле кыз бар микән!

Сабый чагымнан мине
Ул иркәләп үстергән.
Язмыш, аерма мине
Газизем – әниемнән!

Алинә Исмәгыйлева.
IV А сыйныфы.



Сабантуй

Менә ямьле җәй дә җитте,
Көннәр җылынып китте,
Кояш та нурларын сибә,
Димәк, Сабантуй килә.

Сабан туен көтеп алам,
Мин кыштан бирле инде.
Үзем чиктем, үзем тектем,
Күлмәгем әзер инде.

Мин Сабантуйларында
Уеннарда уйнармын.
Ярышларда катнашырмын,
Күп бүләкләр алырмын.

Ләйсән Гәрәева.
IV А сыйныфы.



Ягымлы яз

Кояш та балкып үтә,
Карлар да эреп бетә.
Дөнья җанланып китә.
Димәк, яз килеп җитә!

Хайваннар да үзара
Нәрсәдер сөйләшәләр.
Ә чыпчыклар, чыпчыклар
Күңелле көлешәләр.

Нинди шатлыклы бу яз,
Күбрәк җылыта кояш.
Ныграк җанлана тормыш,
Нинди ягымлы бу яз!

Рәзинә Галипова.
VII А сыйныфы.



Рәссам Светлана ПРИВИНА



Арча районы

Бу як табигый һәйкәлләргә, тарихи истәлекләргә дә бай.
Сез аларның байтагын менә бу рәсемдә дә күрәсез.



Рәссам Юрий ДЕНИСОВ

Без, без, без – уникә без!

Арча районында бик бай бер кыз яши. Беләсезме, кем ул? Нурзилә исемле. Юк, банкир да, эшкуар да түгел ул. Гап-гади авыл кызы. Ташкичү авылында тора. Үзе әле укырга да кермәгән. Ә шулай да бай. Юк, компьютеры да, «Мерседес»ы да юк аның. Һи-и-и... нәрсә ул «Мерседес»... Нурзиләнең 3 абыйсы, 8 апасы янында пүчтәк ул. Кызыкай туганнарының берсен дә аңа алыштырмый.

Менә шулай бер гаиләдә – 12 бала алар! Нурзилә кайчакта апаларының, абыйларының исемнәрен буташтырып та куя. Ә менә әнисе Тәскирә белән әтисе Тәбриз берсен дә буташтырмый. Рәдис, Рамил, Рузилә, Ринат, Миләүшә, Ләйлә, Чулпан, Ләйсән, Энҗе, Гөлфинә, Гөлгенә һәм, әлбәттә, Нурзилә. Берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе акыллы. «4»ле, «5»легә генә укыйлар. Рәдис белән Ринат мәктәпне медальгә тәмамладылар. Рәдис хәзер шушы районның Казанбаш авылында үзе балаларга белем бирә. Ринат Казанда маркетинг булырга укый.





Нурзилә (сулдан беренче) мәктәптән кайтучы апаларын каршы ала.

12 бала арасында иң иркәсе кем дип беләсез? Әлбәттә, төпчекләре Нурзилә инде. Хәер, һәркайсының үз холкы. Чулпан белән Гөлгенә – бик җитди. Миләүшә – сабыр, Гөлфинә – шыпырт, ә Ләйлә исә – тик тормас җан. Тик тормау дигәннән Нурзилә дә кимен куймый. Ишектән кусаң, тишектән керә.

Нурзиләнең апалары һәркөн иртән мәктәпкә китәләр. Юл кырыендагы сукмактан баралар. Тезелешеп. Нәкъ кыр казлары кебек. Нурзилә аларны озатып кала. Дөрес, алар укырга киткәч күңелсез була. Алар кайткач өйгә тагын ямь керә. Барысы да төпчекне кочаклый, башыннан сыйпый.

Тик менә кайчакта Нурзиләнең да апа буласы, йә энекәшенең, йә сеңлекәшенең башыннан сыйпап куясы килә. Их, тагын бер бәби алып кайтсалар. Булыр анысы да, Алла боерса. Ходайның рәхмәте белән алып кайтырга уйлыйлар. Шушы йортка. Анысын абыйсы Рамил белән җиңгәсе алып кайтырга тиеш.

Нурзиләгә пләмәш булачак ул. Таза-сау булып, бәхете белән тусын сабый!



Сәләват күпере



Бу сәхифәбездәге мәзәкләрне, халкыбызның күңел җәүһәрен туплаучы, җыйнаучы буларак, Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәширов тәкъдим иткән иде. Арчалылар гына түгел, без дә көлик-сөеник әле.

Бабайга сорау

– Бабай, әйтче, син кайчан бабай булдың?
– Син тугач, бәбкәм!
– Алайса, моның өчен син миңа нәрсә бирәсең?

Бәхетсез уяткан

– И, әби, нигә син мине тәмле төш күргәндә уяттың инде?
– Соң мин бит белмәдем ләбаса!
– Ничек белмисең инде?! Син бит минем белән бергә чәк-чәк ашап, кәнфит суырып чәй эчтең?!



Чынлап сорый

– Бабай! Әни әйтә, синең кай төшеңдәдер вак ташларың бар, ди.
– Дөрес, балам, бөердә алар.
– Син аларны уйнарга биреп тора алмыйсыңмы?

Ике мактанчык

Куян йомранны очраткан да:
– Син кем? – дигән.
– Аю мин, аю! – дигән йомран.
– Алайса мин – арыслан! – дигән куян.


Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Шүрәле биштәрендә ниләр бар?

1. Бал калагының өлкән туганы.
2. Бүреккә сыйган җан иясе – ерткыч.
3. «Аңгыра» дип даны чыккан хайван.
4. Кечкенәнең иштәше.
5. Үзе җанлы, үзе оча – кош түгел.
6. Сарык белән кәҗә уртасында ни бар?
7. Озыннан кыска.
8. Җидедән олы, тугыздан кече.
9. Шүрәленең капчыгы.
10. Яшелчәләр, аш тәмләткечләр үскән җир.
11. Галигә рәхмәт әйтеп сакалын селкетүче. (Г.Тукай иҗатында байтак ул.)
12. Борында казынырга иң җайлы нәмәстә.
13. Өлешеңә тигәнгә сөен. (Өлкәннәр өчен.)

Җә, малайлар вә кызлар, арчалыларга хәтле кемнәр тизрәк җавапны таба?

Л.Гыйльфанов төзеде.
Арча.



Сәләвәт күпере

4(122) — 2000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкның 1нче битендә
Фәрит Муллахмәт рәсеме

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тасләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 19.4.2000 ел.
Басарга кул куелды 19.4.2000 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 16660 данә. Заказ Э-165.
Бәясе килешү буенча.

POINT®

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Сибгат Хәким

Син йөрәктә минем

Арча, Арча, бөтен дөнья сокланыр як,
Батырларың эштә ярышалар.

Арча ямьле урман-кырлар ягы,
Арча данлы Тукай-Кырлай ягы,
Шуңа күрә горур,
Гөрләп үтә гомер,
Арчалылар, без бит Арчалар!

Арча, Арча, бөтен дөнья сокланыр як,
Таңнар зәңгәр, йортлар зәңгәрләр.

Син йөрәктә минем, җырым төсле,
Таңнар әнкәй беләзеге төсле,
Шуңа күрә горур,
Гөрләп үтә гомер,
Бәхетлеләр мәңге Мәңгәрләр.

Арча, Арча, бөтен дөнья сокланыр як,
Мәңге изге синең туфрагың.

Арча оста читекчеләр ягы,
Читекләргә чигелә Арча даны,
Шуңа күрә горур,
Гөрләп үтә гомер,
Варислары бит без Тукайның.

